ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы Рәисенә җибәрелә торган мәсьәләләр исемлеге хакында (Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында еллык хисапны тәкъдим итүгә бәйле рәвештә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы куйган мәсьәләләр буенча, еллык хисапны тәкъдим итү хакындагы $190^2$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән мәсьәләләр исемлеген Татарстан Республикасы Рәисенә җибәрергә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 13 феврале
№ 31-VII ДСП

2025 елның 13 февралендәге
31-VII ДСП номерлы
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы Рәисенә җибәрелә торган мәсьәләләр исемлеге**

*Икътисад, бюджет*

1. 2025 елда хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм түбән квалификацияле эш урыннарын бетерү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан күрелә торган программа чаралары турында.

2. 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру индикаторларын республика тармак программалары гамәлдә булуның бишьеллык срогы тәмамлануга бәйле рәвештә төзәтүнең максатка ярашлы булуы турында.

3. Санкция басымы шартларында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыру турында.

4. Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү чаралары турында.

5. Һөнәрләр категорияләре буенча бердәм республика цифрлы вакансияләр базасын булдыру мөмкинлеге турында.

6. Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексында авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм сату күләмнәрен арттыруга, хуҗалык итүнең кече рәвешләре, кооперативлар эше нәтиҗәлелеген яхшыртуга юнәлдерелгән кооперация элемтәләрен үстерү буенча Татарстан Республикасында күрелә торган чаралар турында.

7. Республика агросәнәгать комплексын, шул исәптән агросәнәгать комплексының төрле тармакларында цифрлы компетенцияләргә ия булган югары квалификацияле кадрлар әзерләү өлкәсендә, цифрлаштыру турында. Татарстан Республикасында предприятиеләрдә һәм оешмаларда ИТ-технологияләрне гамәлгә кертү нигезендә хезмәт җитештерүчәнлеге үсешенең конкрет уңай мисаллары (сәнәгатьтә, авыл хуҗалыгында, төзелештә) бармы?

8. Авыл җирендә, шәһәр яны районнарыннан тыш, торак төзелешен киңәйтү турында.

9. Торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләргә тарифлар үсешен туктатып тору чаралары турында.

10. Халыкны транспорт белән тәэмин итү сыйфатын, шул исәптән район үзәкләре булган шәһәрләрдә җәмәгать транспорты эшен оештыру өлешендә, яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар турында.

11. Татарстан Республикасында коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләренә газ кертү һәм газ кертүне тәмамлау буенча социаль программаны гамәлгә ашыру турында.

*Социаль сәясәт*

12. Хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга (хәрби хәрәкәтләр ветераннарына) һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль түләүләрнең һәм ярдәм чараларының бердәм республика базасын (реестрын) булдыру мөмкинлеге турында.

13. Махсус хәрби операциядә катнашучыларны, шул исәптән инвалид булып калганнарны, һәм махсус хәрби операциядә һәлак булган катнашучыларның гаилә әгъзаларын реабилитацияләү һәм социальләштерү (медицина, психологик, хезмәт һ.б. шундый реабилитацияләү һәм социальләштерү) системасы үзәген булдыру зарурлыгы турында.

14. Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларының махсус хәрби операциядә катнашучының булу урыны һәм аның статусы (яралы, һәлак булган, хәбәрсез югалган) турында үз вакытында дөрес мәгълүмат алу хокукын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар турында.

15. 2024 елда Татарстан Республикасында Гаилә елын гамәлгә ашыру йомгаклары һәм 2025 елда Татарстан Республикасында гаилә институтына ярдәм итүнең алдагы планнары турында.

16. Опекуннарга һәм попечительләргә Татарстан Республикасы Гаилә кодексының $141^1$ статьясында билгеләнгән түләү күләмен арттыруның максатка ярашлылыгы турында.

17. Опекуннарга (попечительләргә), җәмәгать транспортында попечительлектә булган баладан башка йөргән очракта, түләүсез йөрү хокукын бирү зарурлыгы турында.

18. Инвалидларга республика әһәмиятендәге түләүле юлларда түләүсез йөрү хокукын бирү мөмкинлеге турында.

19. Социаль инфраструктура объектларыннан файдалана алуны тәэмин итү максатларында социаль учреждениеләр һәм сәламәтлек саклау учреждениеләре янында инвалидлар өчен түләүсез парковка урыннарын оештыру зарурлыгы турында.

20. Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча үткәрелә торган эш турында.

*Сәламәтлек саклау*

21. Сәламәтлек саклауның амбулатория-поликлиника учреждениеләрендә беренчел медицина-санитария ярдәменнән файдалана алуны тәэмин итү турында.

22. Сәламәтлек саклау өлкәсендә кадрлар кытлыгын бетерү буенча күрелә торган чаралар турында.

23. Сәламәтлек саклау өлкәсендә ясалма интеллектны гамәлгә кертү өчен, шул исәптән дәвалау учреждениеләрендә гражданнарны беренче мәртәбә кабул итүне камилләштерү максатларында, республикада күрелә торган чаралар турында.

24. Республиканың зур шәһәрләрендәге яңа микрорайоннар территорияләрендә яңа сәламәтлек саклау учреждениеләрен (хастаханәләрне, поликлиникаларны) төзү (ачу) барышы турында, Казан шәһәрендә 1 нче күппрофильле балалар хастаханәсенең яңа бинасын төзү перспективалары турында.

25. Онкологик авырулардан интегүче гражданнарны республиканың шифаханә-курорт учреждениеләрендә дәвалап бетерүне (реабилитацияләүне) оештыру турында.

26. Баланы, әгәр аның анасы һәм (яисә) атасы инвалид булса, табибка кабул итүгә телефоннан яздыруны оештыру зарурлыгы турында.

*Мәгариф, мәдәният*

27. Мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү оешмаларын кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләсен хәл итү чаралары турында.

28. Татарстан Республикасында мәгариф системасын цифрлаштыру турында.

29. Татарстан Республикасында театр эшен үстерү турында.

30. Авылда мәдәният учреждениеләрен (китапханә, клублар) югары тизлекле Интернетка тоташтыру эше турында.

31. Каникул чорында коррекцияле гомуми белем бирү мәктәпләрендә мәктәп яны лагерьларын оештыру турында.

32. Шәһәрләрдәге гомуми белем бирү оешмаларында физик культура белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру турында (шул исәптән спорт заллары төзү, иске биналарда урнашкан шәһәр мәктәпләренең спорт залларын капиталь ремонтлау турында).

33. Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләрендә тренер-укытучыларга ярдәм итүнең комплекслы системасын оештыру турында. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән спортчыларның тренерларына хезмәт хакы түләү дәрәҗәсен арттыруга юнәлдерелгән чаралар турында.

*Иҗтимагый иминлек*

34. Гадәттән тыш хәлләр очрагында халыкны саклауга юнәлдерелгән чаралар турында. Татарстан Республикасы халкына үзәкләштерелгән хәбәр итүнең региональ автоматлаштырылган системасын камилләштерүгә юнәлдерелгән чаралар турында.

35. Үз хезмәткәрләрен яшерену урыны белән тәэмин итүче предприятиеләрдә гражданнар оборонасы саклану корылмаларының (убежищеларның) хәзерге торышы турында.

36. Гражданнар күпләп була торган урыннарда һәм күпфатирлы йортларда, шул исәптән газ кертелгән йортларда, җәмәгать иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасында күрелә торган чаралар турында.

37. Татарстан Республикасында миграция сәясәте өлкәсендә күрелә торган, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының хокукларын яклау өлешендә, чаралар турында.

38. Татарстан Республикасында мәгариф оешмаларында балаларның иминлеген тәэмин итү һәм балигъ булмаганнар арасында хокук бозулар санын киметү буенча күрелә торган чаралар турында.

39. Татарстан Республикасында юл-транспорт һәлакәтләре һәм юлларда һәлак булучылар санын киметү буенча күрелә торган чаралар турында.

40. Татарстан Республикасында, аерым алганда, Казан шәһәрендә, гражданнарны, шулай ук аларның берләшмәләрен җәмәгать тәртибен саклауда катнашуга җәлеп итү буенча күрелә торган чаралар турында.

*Авыл хуҗалыгы, экология*

41. Авыл җирлегендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларга дәүләт ярдәмен арттыру турында.

42. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен эчәргә яраклы сыйфатлы су белән тәэмин итү буенча республикада башкарыла торган эш турында.

43. Эре сәнәгать шәһәрләрендә атмосфера һавасының сыйфатын яхшыртуга һәм кеше сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны булдырмауга юнәлдерелгән чаралар турында.

44. Чүп-чар күләмен киметүгә юнәлдерелгән чаралар турында.

45. Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт турындагы законнарны хуҗасыз агрессив хайваннар проблемасын хәл итү өлешендә үтәү барышы турында.

46. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнешен камилләштерү, алардан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау, авыл хуҗалыгы җирләрен саклап калу, эрозия процессларын киметү һәм мелиорация комплексын үстерү буенча башкарыла торган эш турында.

*Җирле үзидарә мәсьәләләре*

47. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү турында.

48. 2024 елда гражданнарның ихтыярый салым программасын гамәлгә ашыру һәм 2025 елга фаразлар турында.

49. Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру чаралары турында.

50. Җирле үзидарә хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне камилләштерү чаралары турында.